**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре №385-55 2015елның «25» августыннан

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 22 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2008 елның 31 мартындагы 217-30 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 121-18 номерлы, 2013 елның 26 апрелендәге 228-34 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварындагы 284-40 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 351-51 номерлы карарлары редакциясендә)

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 21 июлендәге 59 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставының 92, 93 статьяларына таянып,

Азнакай район Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 22 гыйнварындагы 31 номерлы карары (2008 елның 31 октябрендәге 217-30 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 121-18 номерлы, 2013 елның 26 апрелендәге 228-34 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварындагы 284-40 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 351-51 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3.2. пунктта:

- ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Азнакай муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау,

эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»

- унбишенче абзацта «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

- утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Азнакай муниципаль районы территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, Азнакай муниципаль районының рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

түбәндәге эчтәлекле кырык бишенче абзац өстәргә:

«Азнакай муниципаль районы милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;»;

- кырык бишенче абзацны кырык алтынчы абзац дип санарга.

2. Әлеге карарның 1.1 пунктының икенче абзацы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм әлеге карарны Азнакай муниципаль районының веб-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга:http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин